Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Миңлебай авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

01 ноябрь 2019 ел N 10

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлеге Миңлебай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 15 нче ноябрендә, 15 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Миңлебай авылының Ф.Кәрими урамындагы №1 - 72 йортлары, Ш.Бикчурин, М.Даутова, Яшьләр, Юл урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авылы мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Ш.Бикчурин урамы, 50 нче йорт.

2. 2019 елның 15 нче ноябрендә, 16 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Миңлебай авылының Ф.Кәрими урамындагы №74 – 162 йортлары, Гимаев, Елга, Ишморат урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай урта гомуми белем бирү мәктәбе бинасында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Ф.Кәрими урамы, 33а йорты.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Миңлебай авыл җирлегенең Миңлебай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Миңлебай авылында юлларга асфальт салу, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлегенең Миңлебай авылында сайлау хокукына ия авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

5. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Миңлебай авылы, Ш.Бикчурин урамы, 50 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми

порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Миңлебай
авыл җирлеге башлыгы И.М. Рәхимов